**Татарстан Республикасы Президенты**
**Указы**

## Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында

(Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 16 июнендәге ПУ-223 номерлы, 2006 елның 10 ноябрендәге ПУ-466 номерлы, 2007 елның 21 июнендәге ПУ-323 номерлы, 2008 елның 29 августындагы ПУ-425 номерлы, 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 12 июлендәге Пу-445 номерлы, 2010 елның 25 декабрендәге ПУ-863 номерлы, 2011 елның 15 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы, 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы, 2013 елның 1 февралендәге ПУ-74 номерлы, 2013 елның 18 маендагы ПУ-420 номерлы, 2013 елның 21 сентябрендәге ПУ-925 номерлы, 2013 елның 30 октябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1214 номерлы, 2015 елның 21 июлендәге ПУ-668 номерлы, 2015 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 21 октябрендәге ПУ-950 номерлы, 2017 елның 27 октябрендәге ПУ-976 номерлы, 2018 елның 14 февралендәге ПУ-165 номерлы һәм 2018 елның 18 апрелендәге ПУ-315 номерлы указлары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасын камилләштерү, эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясындагы 2 өлешенә таянып, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты составына Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Президентының беренче урынбасары һәм урынбасарлары, Татарстан Республикасы Президенты Эшләре идарәчесе һәм аларның урынбасары, Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы Тулы вәкаләтле вәкиле, Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчеләре, башка вазыйфаи затлар, шулай ук түбәндәге структур бүлекчәләр керә, дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе секретариаты;

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты;

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе;

Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе;

Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты, аның составына түбәндәгеләр керә: Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе, Граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе, иҗтимагый проектлар бүлеге;

Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты, аның составына түбәндәгеләр керә: Икътисадый анализ идарәсе, җир-мөлкәт мөнәсәбәтләрен координацияләү һәм үстерү бүлеге, Татарстан Республикасы Президентының рәсми чыгышларын әзерләү бүлеге;

Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты;

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе;

Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты;

Татарстан Республикасы Президентының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе;

Татарстан Республикасы Президентының Документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсе;

Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте;

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге;

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының махсус документаль элемтә бүлеге;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге;

Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге;

Татарстан Республикасы Президенты Эшләре идарәсе, аның составына түбәндәгеләр керә:

бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге;

мәгълүмати-техник тәэминат бүлеге;

чараларга хезмәт күрсәтү һәм биналарны карап тору бүлеге;

гомуми бүлек;

Татарстан Республикасы Президентының Мәгълүмат-аналитика идарәсе.

2. Үзгәртеп корырга:

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының оештыру бүлеген Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе итеп;

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының җәмәгатьчелек белән элемтәләр һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлеген Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре идарәсе итеп;

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының хатлар һәм гражданнарны кабул итү бүлеген Татарстан Республикасы Президентының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе итеп;

Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты каршындагы Дәүләт беркетмәсе идарәсен Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе итеп;

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе дәүләт һәм халыкара хокук, шартнамә-хокук эше секторын Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе хокукый экспертиза бүлеге итеп;

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән үзара хезмәттәшлек итү, законнарны системалаштыру секторын Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе закон проектлары эшләү бүлеге итеп;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаментының дәүләт хезмәтен оештыру ягыннан тәэмин итү секторын Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаментының дәүләт хезмәтен оештыру ягыннан тәэмин итү бүлеге итеп;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаментының дәүләт хезмәтен кадрлар белән тәэмин итү секторын Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаментының дәүләт хезмәтен кадрлар белән тәэмин итү бүлеге итеп.

3. Төзергә:

Татарстан Республикасы Президентының Документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсен һәм аның структур бүлекчәләрен – эшләр башкару бүлеген һәм контроль бүлеген;

Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре идарәсендә – иҗтимагый-сәяси берләшмәләр белән хезмәттәшлек итү бүлеген, этник сәясәт бүлеген һәм мәгълүмати-аналитик бүлекне;

Татарстан Республикасы Президентының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсендә – хатлар һәм гражданнарны кабул итү бүлеген, мәгълүмати-аналитик эш һәм контроль бүлеген;

Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсендә – оештыру-протокол бүлеген, хөкүмәт телеграммалары һәм дипломатик календарьлар әзерләү секторын һәм тәрҗемәләр секторын.

Татарстан Республикасы Президенты Эшләре идарәсенең гомуми бүлеге беркетмә секторын, тәрҗемәчеләр төркемен һәм машинкада бастыру бюросын (секторлар хокукында) үз эченә ала, дип билгеләргә.

6. Үз көчен югалтты (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 18 маендагы ПУ-420 номерлы Указы).